**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Аксубай муниципаль районы
Иске Ибрай авыл җирлеге
423078 Иске Ибрай авылы
Кооператив урамы, 2 йорт
тел. (факс) 884344- 4-63-72

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Совет Староибрайкинского сельского
поселения Аксубаевского
муниципального района
423078 с. Старое Ибрайкино
улица Кооперативная, д.2
тел. (факс) 884344-4-63-72


# КАРАР

№ 82 2024 елның 27 мае

Җирле салымнар буенча вакытында түләнеп бетмәгән салымларны һәм пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип табуның өстәмә нигезләре турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә, Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең «Түләүгә өметсез дип танылган, вакытында түләнеп бетмәгән салымларны һәм пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычларны бетерү тәртибен һәм вакытында түләнеп бетмәгән салымларны, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану шартларын раслаучы документлар исемлеген раслау турында» 19.08.2010 N ЯК-7-8/393@ боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Җирле салымнар буенча вакытында түләнеп бетмәгән салымларны, һәм бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә (алга таба - бурыч):

- варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;
- 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;
- Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларда 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.

2. Салым түләүченең бурычын исәптән чыгару салым органы тарафыннан әлеге карар һәм җирле салымнар суммалары буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар нигезендә башкарыла:

1) әлеге карарның 1.1 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) үлем белән бәйле рәвештә салым органнарында физик затны исәптән төшерү турында мәгълүмат;

в) мирас хокукы турында таныклык бирү турында мәгълүматлар булмау турында салым органы белешмәсе;

2) әлеге карарның 1.2 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

а) оешма, шәхси эшмәкәр, шәхси эшмәкәр статусын югалткан физик зат исәпкә алынган урын буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) салым гамәлдән чыгарылган норматив хокукый акт(исеме, датасы, номеры) турында мәгълүмат;

3) әлеге карарның 1.3 пунктында күрсәтелгән нигез булганда, салым органының 500 сумнан артмаган бурыч булу турында белешмәсе.

3. 2021 елның 05 мартындагы 18 номерлы "Бурычларны, пенялар буенча бурычларны һәм җирле салымнар буенча штрафларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында" карарны үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Иске Ибрай авыл җирлеге Советының финанс һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы
Иске Ибрай авыл җирлеге башлыгы М.Г.Минигулов